| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 01 апреля 2016 г. г. Казань № 82

2015 елның 8 июненләне 154 санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында" 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 2015 елның 5 сентябрендәге 643 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында" 2010 елның 18 ноябрендәге 906 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында үрнәк нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында" 2015 елның 17 ноябрендәге 862 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарларына нигезләнеп б о е р а м:

1. 2015 елның 8 июнендәге 154 санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктындагы "коммерциясез оешмалар, шул исәптән социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар" сүзләрен "шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмалар" сүзләренә алмаштырырга.

3.3 пунктындагы "иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре санынннан Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар вәкилләре" сүзләрен "иҗтимагый берләшмәләр һәм социаль

юнәлештәге коммерциясез оешмалар вәкилләре гражданнары” сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазифаларын, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясендәге бүтән субъектларның дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, муниципаль вазифаларны һәм муниципаль хезмәт вазифаларын биләгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан биштән бер өлешеннән артмаган күләмдә кертелә ала”;

3.8 абзацының 4 пукнтындагы “кандидат вазифасына” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов